**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАКТАЛАЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423751, Такталачык авылы,
Г.Авзал ур.,48 нче йорт.
Тел/факс 3-44-57
e-mail : tak-akt@yandex.ru

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ТАКТАЛАЧУКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423751,с.Такталачук, ул.Г.Авзал,
дом 48.
Тел/факс 3-44-57.
e-mail : tak-akt@yandex.ru

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

21 август 2024 ел № 15

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы, 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы "Муниципаль вазыйфа яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында" Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Гамәлдән чыккан дип танырга:

- "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Такталачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан күрсәтелү хакында нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының 2016 елның 17 мартындагы 5 номерлы карарын;

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Советының 2021 елның 10 нчы апрелендәге 7 номерлы "Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Советының 2016 елның 17 мартындагы 5 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Такталачык авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан тапшырылуы турында Нигезләмәне раслау хакында»гы карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмати порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Актаныш муниципаль районы
Такталачык авыл җирлеге Советы белән рәислек итүче Л.С.Минхузин